Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге Советы

КАРАР

№114 «25» октябрь 2019 ел

Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәтне биләүче затлар тарафыннан үзләренең хезмәт (вазифа) бурычларын үтәүгә, беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, «Вазыйфаи хәлләренә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. «Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәтләрне биләүче затлар тарафыннан үзләренең хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәү белән, беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга катнашу белән бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе хакында» Нигезләмәне расларга (1нче кушымта).

2.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советының «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында хәбәр итү тәртибе турында» 2014 елның 25 февралелендәге 116 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге
Советы рәисе С.В. Белов